Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Рус Әшнәге авылы 2022 елның 11 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карары проекты хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 19, 87, 88, 89 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карары проектын беренче укылышта 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проекты буенча 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проекты буенча 3 нче кушымтага ярашлы рәвештә гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне

исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзергә:

Хаҗиев Вәкил Хашимович – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

Абдуллина Илсияр Бәйрәмхановна – оештыру комитеты әгъзасы;

Шәйхетдинов Нурислам Рәсимович – оештыру комитеты әгъзасы.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2022 елның 17 июленә 10.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт.

5. Оештыру комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәгеавыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” гы карар проектын, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм икенче укылышта кабул итү өчен карар проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советы каравына кертүне тәэмин итәргә.

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәгеавыл җирлеге Башлыгы В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Рус Әшнәгеавыл
җирлеге Советының
2022 елның 11 июлендәге
4  номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәгеавыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның  44 маддәсе, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының  87, 88, 89 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы  КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советының 2015 елның 16 апрелендәге 9 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының 2016 елның 1 декабрендәге 20 номерлы, 2017 елның 25 июлендәге 6 номерлы, 2018 елның 27 апрелендәге 5 номерлы, 2018 елның 12 октябрендәге 10номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге 6 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны  дәүләт теркәвенә алынганнан соң Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда,  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең  Рус Әшнәге авылы,  Мәктәп урамы, 9а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.
4. Карар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәгеавыл
җирлеге Советының
2022елның 11 июлендә
4 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
“Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 5 маддәдә:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү;

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

7) җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм гаммәви спорт үсеше өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) җирлекнең архив фондларын формалаштыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәү тора, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

10) адресация объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан гайре), җирлек чикләрендә

планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм мәет кую (җирләү) урыннарын карап тоту;

16) җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, субүлүне, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессиональара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының гаммәви ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтә алуын тәэмин итүне дә кертеп;

20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү турында карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның чик параметрларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата куелган мәҗбүри таләпләргә, җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның билгеләнгән кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата куелган мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар.";

2) 6 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 18 пунктча өстәргә:

"18. алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.";

3) 16 маддәнең 9 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

"7) инициатив проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.";

20 маддәнең 1 өлешен "һәм җирлек җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары,"сүзләреннән соң "инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре турында фикер алышу" сүзләрен өстәргә;

4) 22 маддәдә:

а) 2 өлештә “анда сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда” сүзләреннән соң “яисә территориясенең бер өлешенең” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлектәге 3 өлешне өстәргә:

“3. Гражданнар җыены авыл җирлеге составына керүче торак пункт территориясендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннан чыгып, җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.”;

6) 23 маддәдә:

а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

“Гражданнарның инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда уналты яшькә җиткән инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яки аның бер өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.”;

б) 23 маддәнең 7 өлешендәге 1 пунктына “яки җирлек халкы” сүзләрен өстәргә;

7) 40 маддәнең 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7) Россия Федерациясе гражданлыгын яки Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын (аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы), чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәте яисә башка документы булып Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган ул документны туктату, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;”;

8) 46 маддәнең 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) Россия Федерациясе гражданлыгын яки Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын (аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы), чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәте яисә башка документы булып Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган ул документны туктату, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;”;

9) 49 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Җирлекнең башкарма комитеты җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) җирлек музейларын төзү;

2) җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

4) җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә ярдәм күрсәтү һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

6) җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

7) муниципаль янгын сагын булдыру;

8) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

9) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык күрсәтүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә ярдәм күрсәтү;

10) “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

11) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнарга бирү;

12) җирлек территориясендә хуҗаларсыз гына яшәүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;

13) “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында” 23.06.2016 ел № 182-ФЗ Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

14) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итүгә;

15) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән вакытка торак урыны бирү;

17) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.”;

10) 68 маддәнең 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4. Муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен вазыйфаларны билгели торган яисә үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектлары тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы

законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җайга салу йогынтысын бәяләү үткәрелергә мөмкин, түбәндәгеләрдән гайре:

1) җирле салымнар һәм җыемнар билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актлары проектлары;

3) гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне.”.

11) 79 маддәдә:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Җирлек Советының җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм җирлек Советына бюджет турындагы карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән норматив хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына.”;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге өченче абзацны өстәргә:

“Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын билгеләүче һәм халыкка гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү буенча юнәлешләрен билгеләүче документларда;”;

өченче - җиденче абзацларны тиңдәшле рәвештә дүртенче - сигезенче абзацлар дип санарга;

12) 81 маддәдә:

а) 1 өлешне “(торак пунктның” сүзләреннән соң “яки аның территориясенең бер өлеше” сүзләре белән тулыландырырга;

б) 2 өлештә “һәм 4.1” сүзләрен “,4.1 һәм 4.3” сүзләренә алмаштырырга.

13) 88 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Җирлек Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында җирлек Советы карары, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш: http://pravo.tatarstan.ru -Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында; http://pravo-minjust.ru кат http://право-минюст.рф - челтәр басмасы буларак теркәлү: № ФС77-72471, 05.03.2018). Җирлек башлыгы теркәлгән җирлек Уставын, җирлек Советының җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан муниципаль берәмлек уставы, муниципаль хокукый акт турында муниципаль

берәмлек уставына үзгәрешләр кертү хакында мәгълүматларны “Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында” 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 маддәсендәге 6 өлешендә каралган Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамә килеп ирешкән көннән алып җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.”.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәгеавыл
җирлеге Советының
2022 елның 11 июлендәге
4 номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә түбәндәге үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәгеавыл җирлеге Советына кертелә:

| № п/п | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча юллана: 422642, ТР, Балык Бистәсе районы,Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт; почта аркылы: 422642, ТР, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт яисә (88-43-61)24643 факсы буенча.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты рәсми рәвештә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көннән башлап эш көннәрендә сәг. 8 дән 17 сәгатьләрдә 2022 елның 15 июленә кадәр кабул ителә.

Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422642, ТР, Балык Бистәсе районы,Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт; почта аркылы: 422642, ТР, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт яисә (88-43-61)24643 факсы буенча.

2. Заявкалар эш көннәрендә сәг. 8 дән 17 сәгатьләрдә ачык (гавами) тыңлаулар датасына чаклы 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителәләр.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетына тапшырыла

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәгеавыл җирлеге Башлыгы В.Х.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Рус Әшнәгеавыл
җирлеге Советының
2022 елның 11 июлендәге
4 номерлы карарына
кушымта №3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" гы карар проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба – гавами тыңлаулар, карар проекты тиңдәшле рәвештә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 19 маддәсе һәм әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар – җирлек Советына гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган районда көн итүчеләр.

3. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмый гына катнашучылар булып җирлекнең һәммә кызыксынучы кешесе торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 1 сәг. алдан башлана.

5. Гавами тыңлауларда җирлек Башлыгы яки аның йөкләмәсе (кушуы) буенча җирлек Башкарма комитеты җитәкчесе, карар проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитеты рәисе рәис була.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

9. Гавами тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артык түгел.

11. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм алып баруга комачауларга хаклы түгел.

13. Гавами тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны утырышлар залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15. Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык искәртү һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Гавами тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә Совет материалларында саклана.

17. Гавами тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) оештыру комитеты тарафыннан әзерләнә.

18. Гавами тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19. Гавами тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы В.Х.Хаҗиев